ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРЖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре. 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«14» февраль 2020 ел № 62

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәдәни-массакүләм чаралар үткәргәндә туклануны, яшәүне, транспортта йөрүне тәэмин итү чыгымнарын һәм матди тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 елның 09 декабрендәге 476 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, мәдәни-массакүләм чараларны матди тәэмин итүгә, мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларны туклану, яшәү һәм йөртү белән тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны рациональ файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәдәни-массакүләм чаралар үткәргәндә туклануны, яшәүне, транспортта йөрүне тәэмин итү чыгымнарын һәм матди тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2019 елның 09 декабрендәге 476 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 09 декабрендәге 476 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәдәни-массакүләм чаралар үткәргәндә туклануны, яшәүне, транспортта йөрү чыгымнарын һәм матди тәэмин итү Тәртибенә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары О.А.Баженовага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **А.С. Авдеев**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 09 декабрендәге 476 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында мәдәни-массакүләм чаралар үткәргәндә туклануны, яшәүне, транспортта йөрү чыгымнарын һәм матди тәэмин итү Тәртибенә кушымта (карарның 14 февраль 2020 ел, № 62 яңа редакциясендә)

## Мәдәни-массакүләм чаралар үткәргәндә чыгымнар нормалары

| **Мәдәни-массакүләм чараларның исеме** | **Кеше өчен чыгым нормалары көнгә (сум.)** |
|---|---|
| Чарада катнашучыларны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районыннан кимендә 3 сәгатьлек 200 км озынлык һәм аннан да күбрәк ераклыктагы юлда тукландыру | 200 |
| Катнашучыларның чара үткәрү урынында яшәүләре:<br>-ТР территориясендә;<br>- РФ территориясендә, аннан читтә. | 550<br>1000 |
| Бару | Йөртү документлары белән расланган факттагы чыгымнар күләмендә |

Искәрмә: мәдәни-массакүләм чаралар уздыру урыннарында оешкан төстә туклану белән тәэмин итү өчен акчасыз исәп-хисап ясау мөмкинлекләре булмаганда, мәдәни-массакүләм чараларда катнашучыларга югарыда күрсәтелгән нормалар буенча акчаларны ведомость буенча кулга бирү рөхсәт ителә.